КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 21 май г.Казань № 412

Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә тукланыны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чаралары турында

Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә тукланыны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чараларын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә тукланыны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чараларын тормышка ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибен;

Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга

социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирү тәртибен.

2. Бу карарның гамәле 2020 елның 21 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 21 май, 412 нче
карары белән расланды

**Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә тукլануны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чараларын тормышка ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибе**

1. Бу коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә тукլануны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чараларын тормышка ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибе (алга таба – Тәртип) яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары (алга таба – социаль хезмәт күрсәтү оешмалары) хезмәткәрләренә тукլануны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чараларын тормышка ашыру чыгымнарын Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслар белән тәэмин итү механизмын билгели.

2. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 23 июненә кадәр чикләү чаралары (социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның, шулай ук эш сменасының дәвамлылыгы 14 календарь көннән дә ким булмаган социаль хезмәт күрсәтү оешмасы хезмәткәрләренең социаль хезмәт күрсәтү оешмасында яшәвен вакытлыча изоляцияләү (обсервацияләү)) каралган «Дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында махсус эш режимы турында» 2020 ел, 19 май, 406 нчы карары белән билгеләнгән махсус эш режимында үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә тукլануны оештыруга, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүгә тотыла.

3. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә бер хезмәткәргә 1 көнгә 250 сум исәбеннән

туклануны оештыру чараларын тормышка ашыру, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен дәвамлылыгы 14 календарь көннән ким булмаган бер эш сменасына бер хезмәткәргә 7 500 сум исәбеннән стимуллаштыру характерындагы түләүләр (алга таба – шул ук эзлеклелектә туклануны оештыру һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр) бирү чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә бирелә.

4. Бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

5. Туклануны оештыру һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасын тоту Министрлык тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси исәп аша гамәлгә ашырыла.

6. Министрлык, бу Кагыйдәләрнең 2 нче пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыру максатларында, бюджет һәм автоном учреждениеләр булган социаль хезмәт күрсәтү оешмалары белән Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр бирү шартларын һәм күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» 2016 ел, 30 декабрь, 1052 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанслар белән тәэмин итүгә бәйле булмаган башка максатларга субсидияләр бирү шартларын һәм күләмен билгеләү тәртибе нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының «Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы дәүләт бюджет яки автоном учреждениесенә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә субсидияләр бирү турындагы килешүнең бертип формасын раслау хакында» 2016 елның 22 декабрендәге 17-148 номерлы боерыгы белән расланган форма буенча Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешүләр төзи.

7. Министрлык ай саен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына туклануны оештыру һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләр чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә заявка (алга таба – заявка) җибәрә.

8. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы ай саен, заявка кергән көннән биш эш көне эчендә, финанслауның иң чик күләмнәрен Министрлыкка җиткерә.

9. Министрлык финанслауның иң чик күләмнәре Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан җиткерелгәннән соң өч эш көне эчендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә автоном һәм бюджет социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына

тукланыны оештыруга һәм стимуллаштыру характерындагы түләүләрне башкаруга субсидия бирүне;

финанслауның иң чик күләмнәрен казна учреждениеләре булган социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына социаль хезмәт күрсәтү оешмалары заявкалары буенча Министрлык тарафыннан билгеләнгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә җиткерүне.

10. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары Министрлыкка ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 8еннән дә соңга калмыйча, бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра.

11. Министрлык ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 15еннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына бу Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча Татарстан Республикасы бюджетының башкарылган чыгымнары турында хисап тапшыра.

12. Министрлык һәм социаль хезмәт күрсәтү оешмалары бирелә торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасының максатчан файдаланылмавы өчен Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә җавап бирә.

13. Бу Тәртип нигезендә бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчасыннан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 21 май, 412 нче
карары белән расланды

## Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр (алга таба – шул ук эзлеклелектә социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, стимуллаштыру характерындагы түләүләр) бирү тәртибен һәм шартларын билгели.

2. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 23 июненә кадәр чикләү чаралары (социаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларның, шулай ук эш сменасының дәвамлылыгы 14 календарь көннән дә ким булмаган социаль хезмәт күрсәтү оешмасы хезмәткәрләренең социаль хезмәт күрсәтү оешмасында яшәвен вакытлыча изоляцияләү (обсервацияләү) каралган «Дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында махсус эш режимы турында» 2020 ел, 19 май, 406 нчы карары белән билгеләнгән махсус эш режимында үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә дәвамлылыгы 14 календарь көннән ким булмаган бер эш сменасына 7 500 сум күләмендә билгеләнә.

3. Стимуллаштыру характерындагы түләү бу Тәртипнең 2 нче пунктында билгеләнгән күләмнән чыгып гамәлгә ашырыла.

Эш сменасының дәвамлылыгы 14 календарь көннән артыграк булган очракта, стимуллаштыру характерындагы түләүләр фактта эшләнгән көннәр өчен дәвамлылыгы 14 календарь көннән ким булмаган бер эш сменасына 7 500 сум күләменнән чыгып гамәлгә ашырыла.

Хезмәткәр үз теләге белән эш сменасын өзгән очракта, стимуллаштыручы характердагы түләүләр фактта эшләнгән көннәр өчен дәвамлылыгы 14 календарь көннән ким булмаган бер эш сменасына 7 500 сум күләменнән чыгып гамәлгә ашырыла.

Хезмәткәр авыру белән (яңа коронавирус йогышлы авыруыннан тыш) бәйле рәвештә эш сменасын өзгән очракта, стимуллаштыру характерындагы түләүләр эш сменасын өзгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча ачылган вакытлыча хезмәткә яраксызлык кәгазе булганда фактта эшләнгән көннәр өчен билгеләнә.

4. Эш сменасы чорында хезмәт вазыйфаларын башкарганда социаль хезмәт күрсәтү оешмасы хезмәткәрендә яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган, яңа коронавирус йогышлы авыруы белән авырган кеше белән расланган контакты булган хезмәткәр тарафыннан эш сменасы чорында эшләве мәҗбүри туктатылган очракта, аның тарафыннан изоляция режимын үтәү максатларында аларның бу Тәртипнең 2 нче пунктында каралган күләмдә стимуллаштыру характерындагы түләү алу хокукы саклана.

5. Стимуллаштыру характерындагы түләүләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 21 май, 412 нче карары белән расланган Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә тукланунны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чараларын тормышка ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибе нигезендә социаль хезмәт күрсәтү оешмаларына бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән башкарыла.

6. Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыру акчасын максатчан файдалану өчен җавап бирә.

Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә тукланыны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чараларын тормышка ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибенә
2 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
2020 елның ______________ына (енә) яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә тукланыны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чараларын тормышка ашыру чыгымнары турында хисабы

Тапшыру вакыты: айлык.
Тутырыла: хисап елы башыннан арта бара торган йомгак белән.
Үлчәү берәмлеге: сум (өтердән соң икенче унарлы билгегә кадәр төгәл итеп).

| Т/с | Хезмәткәрләр саны, кеше | План | | | | Финанслау | | | | Касса чыгымы | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Чыгымнар барлыгы | шул исәптән түбәндәгеләргә | | | чыгымнар барлыгы | шул исәптән түбәндәгеләргә | | | хезмәткәрләр саны, кеше | чыгымнар барлыгы | шул исәптән түбәндәгеләргә | | |
| | | | стимуллаштыру характерындагы түләүләрне тәэмин итүгә | | Хезмәткәрләрне туклану белән тәэмин итүгә | | стимуллаштыру характерындагы түләүләрне тәэмин итүгә | | хезмәткәрләрне туклану белән тәэмин итүгә | | | стимуллаштыру характерындагы түләүләрне тәэмин итүгә | | хезмәткәрләрне туклану белән тәэмин итүгә |
| | | | эш хакы | хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр | | | эш хакы | хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр | | | | эш хакы | хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| | | | | | | | | | | | | | | |

Җитәкче ______________________ ____________ / ______________________
(вәкаләтле зат) (вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

М.У.

Үтәүче ______________________ ____________ / ______________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

______________________

Яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә тукклануны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чараларын тормышка ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү тәртибенә
1 нче кушымта

Форма

______________________________________________ның(нең)
(оешма исеме)

2020 елның _____________ына (енә) яңа коронавирус йогышлы авыруы ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус йогышлы авыруын йоктыру рискы төркемнәреннән булган затларга социаль хезмәтләр күрсәтүче дәүләт стационар социаль хезмәт күрсәтү оешмалары хезмәткәрләренә тукланууны, махсус хезмәт шартлары һәм өстәмә йөкләнеш өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр бирүне оештыру чараларын тормышка ашыру чыгымнары турында хисабы

Тапшыру вакыты: айлык.
Тутырыла: хисап елы башыннан арта бара торган йомгак белән.
Үлчәү берәмлеге: сум (өтердән соң икенче унарлы билгегә кадәр төгәл итеп).

| Т/с | Хезмәткәрләр саны, кеше | План | | | | Финанслау | | | | Касса чыгымы | | | | | Тайпылыш | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | чыгымнар барлыгы | шул исәптән түбәндәгеләргә | | | чыгымнар барлыгы | шул исәптән түбәндәгеләргә | | | хезмәткәрләр саны, кеше | чыгымнар барлыгы | шул исәптән түбәндәгеләргә | | | хезмәткәрләр саны, кеше | чыгымнар барлыгы | шул исәптән түбәндәгеләргә | | |
| | | | стимуллаштыру характерындагы түләүләрне тәэмин итүгә | | хезмәткәрләрне туклану белән тәэмин итүгә | | стимуллаштыру характерындагы түләүләрне тәэмин итүгә | | хезмәткәрләрне туклану белән тәэмин итүгә | | | стимуллаштыру характерындагы түләүләрне тәэмин итүгә | | хезмәткәрләрне туклану белән тәэмин итүгә | | | стимуллаштыру характерындагы түләүләрне тәэмин итүгә | | хезмәткәрләрне туклану белән тәэмин итүгә |
| | | | эш хакы | хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр | | | эш хакы | хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр | | | | эш хакы | хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр | | | | эш хакы | хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 (18 гр. + 19 гр. + 20 гр.) | 18 (8 гр. – 13 гр.) | 19 (9 гр. – 14 гр.) | 20 (10 гр. – 15 гр.) |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Җитәкче ______________________ ______________________ / __________________________________
(вәкаләтле зат) (вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

М.У.

Үтәүче ________________________________ ______________ / __________________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)